РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

09.12.2022 ел №149

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Хәрби хезмәт узу яисә Россия Федерациясе
Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә
ирекле ярдәм күрсәтү чорына муниципаль
милектәге мөлкәтне арендалау шартнамәләре
буенча аренда түләвен кичектереп тору һәм
штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда
шартнамәләрен өзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 октябрендәге 3046-р номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 16 ноябрендәге 2507-р номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар, аларда юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган бер үк физик зат арендатор булып торган, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт үтәүче, йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән күрсәтелгән физик затларга, шул исәптән

шәхси эшмәкәрләргә, яки юридик затның гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган физик затларга түбәндәгеләрне бирүне тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектерү (алга таба – аренда түләвен кичектерү);

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда килешүләрен өзү мөмкинлекләре.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен түләүне кичектерү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат тарафыннан аренда түләвен кичектерү чорына шартнамә буенча арендалана торган мөлкәттән файдаланмау;

арендатор, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәт узу статусын раслаучы документлар күчермәләре белән аренда түләвен түләүне кичектерү турында хәбәрнамә яисә күрсәтелгән контрактлар төзелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән хәрби хезмәт узу турында Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә контракт яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турындагы контракт күчермәсен төзү турындагы белдерү күчермәсен җибәрә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән арендаторга әлеге карарның 4 пункты нигезендә исәпләнә торган чорга аренда түләвен кичектерү бирелә;

аренда түләве буенча бурыч аренда шартнамәсенә өстәмә килешү нигезендә аренда түләвен кичектереп тору чоры тәмамланганнан соң этаплап, айга бер тапкыр, тигез түләүләр белән түләнергә тиеш, аларның күләме аренда килешүе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмый;

аренда түләвен кичектерүгә бәйле рәвештә арендатор түләргә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда башкаларның акчаларыннан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендаторның аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәвенә бәйле башка җаваплылык (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүе белән каралган очракларда) кулланылмый.

3. Аренда килешүен әлеге карарның 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча өзү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

арендатор, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәт узу статусын раслаучы документларның күчермәләрен кушып аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә яки күрсәтелгән контрактлар төзелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән хәрби хезмәт узу турында Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә контракт яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турындагы контракт төзү турындагы белдерү күчермәсен җибәрә;

арендага бирүче аренда килешүен өзү турында хәбәрнамә алган көннән аренда килешүен өзәргә тиеш;

аренда килешүе өзелүгә бәйле штрафлар, башкаларның акчаларыннан файдаланган өчен процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда да).

4. Аренда түләвен түләүне кичектерү срогы 90 көнгә арттырылган мобилизации срогы дип исәпләнә һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затның мобилизация чорында бурыч үтәгәндә алынган имгәнүдән (яраланудан, җәрәхәттән, контузиядән) яки авырулардан дәвалануга хастаханәләрдә, госпитальләрдә, башка медицина оешмаларында стационар шартларда булу чорына озайтыла, ә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затны билгесез югалган – шулай ук аны билгесез югалган дип тану турында суд карары гамәлдән чыгарылганчыга кадәр яисә суд тарафыннан аны үлгән дип игълан ителгәнче.

Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затның үлүе (вафат булуы) очрагында, әгәр ул мобилизация чорында яки мобилизация чорында алынган имгәнү (яралану, җәрәхәтләр, контузия) яки авыру аркасында күрсәтелгән чордан соң үлсә (вафат булса), шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аны I төркем инвалид дип таныган очракта кичектереп тору чоры өчен аренда түләве алынмый.

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә имгәнүгә (яралануга, җәрәхәтләргә, контузиягә) яки үлемгә яисә I төркем инвалид дип танылуга китергән авыруларның мобилизация чоры белән сәбәп бәйләнеше хәрби-табиб комиссияләре һәм (яки) федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан билгеләнә.

5. Физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар, аларда юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган бер үк физик зат арендатор булып торучы муниципаль предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә итү хокукында яки муниципаль учреждениега оператив идарә итү хокукында беркетелгән муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча муниципаль предприятиеларга һәм муниципаль учреждениеларга Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт үтәүче, йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән күрсәтелгән физик затларга, шул исәптән шәхси эшмәкәрләргә, яки юридик затның гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булган физик затларга түбәндәгеләрне бирүне тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектерү;

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда килешүләрен өзү мөмкинлекләре.

6. Әлеге карарның 5 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен түләүне кичектерү әлеге карарның 2 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

7. Аренда килешүен әлеге карарның 5 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча өзү әлеге карарның 3 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

9. Әлеге карар 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары Г.М. Җамалетдинов